**Балтач муниципаль районы**

**МБГБУ "Шубан ТГБМ"**

# Проект

# «Мин яши торган урам тарихы математик саннарда»

**Житэкчесе:Шарипова Л.У.**

**Башкаручы: Даминов Ф.Р.**

**2021-2022нче уку елы**

Кереш

Мин Даминов Фаил 1нче сыйныф укучысы . Бүген мин үзем яши торган урам тарихын математик саннар белән сөйләргә телим.

Проектны эшләү өчен мин максат куйдым :

1. Мин яши торган урамны математик саннардан чыгып өйрәнү

Бурычлар.

1. Урамдагы йортларны санау.

2. Урамыбыздагы иң өлкән һәм иң яшь кешене белү;

3. Урамыбызның математик тарихын өйрәнү ;

Безнең урамның исеме Яшьләр урамы. Мин Яшьләр урамының 20 нче йортында яшим.

Безнең урам 1980нче елда төзелгән. Шулай ук 1нче йорт та 1980 елда барлыкка килгән. Минем әби белән бабай бу урамга беренче булып аяк баскан.

1981 елда 2нче йорт төзеп Гатауллин Нурулла абыйлар кергән.

1981 елның 7 ноябрендә 1нче булып Яшьләр урамына ут кертелгән.

1982 елда башка йортлар төзелгән .

1982 елда Яшьләр урамына 1нче су колонкасы куелган.

1993 елда Яшьләр урамына газ кертелгән.

Хәзерге вакытта Яшьләр урамында 33 кеше гомер итә. Шулардан иң өлкән кеше Мөхәммәтҗанова Әминә апа.

1980 елда иң беренче булып бу урамда бәби туган. Ул минем әтием Даминов Рамиль

Проектны башкарып мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем :

1. Безнең урамыбыз бик тыныч. Монда бары тик яхшы кешеләр генә яши.

2. Урамым тарихы математик саннарга бай;







